**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

2022 елның 28 феврале №91

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2013 елның 16 декабрендәге 213 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 07 сентябрендәге 280 номерлы карар редакциясендә)**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2013 елның 16 декабрендәге 280 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына (2020 елның 07 сентябрендәге 280 номерлы редакциядә) түбәндәге чикләрдә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Советы 2022 елның 4 февралендәге 39 номерлы, генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул итте;

1.2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге Советы 2022 елның 4 февралендәге 39 номерлы, генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул итте;

1.3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы 2022 елның 28 гыйнварындагы 43 номерлы, генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул итте;

1.4. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Советы 2022 елның 28 гыйнварындагы 43 номерлы, генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул итте;

1.5. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш

авыл җирлеге Советы 2022 елның 31 гыйнварындагы 45 номерлы, генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул итте;

1.6. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы 2022 елның 28 гыйнварындагы 41 номерлы, генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул итте;

1.7. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге советы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге советы 2022 елның 1 февралендәге 40 номерлы, генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул итте.

2. Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Россия Федерациясенең территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгарырга.

2. Әлеге карарны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык, ТКХ һәм төзелеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль район Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Советы рәисе Н.А. Вазыйхов